СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

14 июнь, 1997ел.
ШИМБӘ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 64 (8076) | Бәясе билгеләнгәнчә

## Иртәгә - медицина хезмәткәрләре көне

# ИЛДӘ ХЕЗМӘТ, КЫРДА ХЕЗМӘТ...

## «Уңыш - 97» пресс - үзәге хәбәр итә

Авылда эш темпы сүрелми. Бүгенге көндә сабан культураларын тукландыру эше азагына якынлашып килә. Мичурин исемендәге, «Рассвет», Хафизов исемендәге хуҗалыклар бу эшне нигездә тәмамладылар инде, әмма «Татарстан», «Заря», «Правда» ассоциацияләрендә сабан культураларын шактый мәйданда тукландырасы бар әле.

Чәчүлекләрне гербицид белән эшкәртүгә дә игътибар кимеми. Бу эшне Киекле, Әлмәт, Мичурин исемендәге крестьян хуҗалыклары ассоциацияләре аеруча уңышлы дәвам итәләр, ә менә сөт - май комбинатының һәм РСУның Илюткино һәм «Мамык» ярдәмче хуҗалыкларында чүп үләннәре белән көрәшүгә әллә ни зур игътибар бирелми.

Район хуҗалыкларында рәт аралары эшкәртелгән кукуруз басулары мәйданнары көннән - көн арта барса да сигез хуҗалык, шул исәптән «Правда», «Үрнәк», «Чирмешән» һәм башка КФХАларда бу эшкә бөтенләй дә керешмәделәр әле. Аның каравы, Мичурин исемендәге, Киекле һәм «Алга» хуҗалыкларында «кыр патшасы» мәйданнарының 400 - 304 гектарының рәт аралары эшкәртелде инде.

Районның җиде хуҗалыгы - Синдряков, Хафизов, Муса Җәлил, Кузнецов исемнәрендәге, «Родина», «Заветы Ильича», «40 лет Победы» ассоциацияләрендә витаминлы үлән оны ясау агрегатлары эшкә җибәрелде. Кыска вакыт эчендә алар 15 тонна витаминлы үлән оны җитештерделәр.

Шикәр чөгендере плантацияләрендә тракторлар рәт араларын эшкәртсәләр, хатын - кызлар чөгендер сирәклиләр.

Бүгенге көнгә районның байтак хуҗалыклары күпьеллык үләннәрне чаптыруга керештеләр инде.

## ПЕЧӘНГӘ ТӨШТЕЛӘР

Байтак хуҗалыклар әле печәнгә төшмәгән бер вакытта «Родина» КФХАндә күпьеллык үләннәрнең 50 гектарлы бер мәйданы тулысынча теземнәргә салынган иде инде. «Беларусь» тракторларына тагылган КРН - 2,1 чапкычлары белән Сергей Куприянов һәм Виталий Герасимов бу эшне ике көндә тәмамлаганнар булып чыкты. Без бирегә булган көнне икенче участокка күчеп киләләр иде алар.

- Үлән куе да, биек тә булып үскән,- диделәр егетләр безгә - ходай язып үзвакытында, сыйфатлы килеш киптереп, өеп тә куйсак, маллар өчен бер дигән азык буласы инде...

Хуҗалыкта азыкны быел да күп итеп хәзерлиселәренә шикләнүчеләр юк. Ни өчен дигәндә, һава шартлары көйсезрәк килгән елларның элеккегеләрендә дә родиналылар терлек азыгын әз хәзерләмиләр иде. Ә быел... Яңгыры явып тора, шуның өстенә аның ясалмалысын да сиптереп торалар әле. Техникалары да сынатырлык түгел. Хәер, аның сын күпкә алдан, кыш керүгә үк кайгырта башлаганнар иде инде. Әнә, елның - елында «Беларусь»ена печән өйгеч куеп эшләүче тәҗрибәле механизатор Анатолий Сафронов үз техникасын, кем әйтмешли, сәгать механизмыдай төгәл эшләрлек итеп көйләп куйды. Гамәлдән чыгарылган «Нива»лар базасында ясалган «Ветерок» печән туплагыч агрегатлар хуҗалары Виталий Ефимов белән Николай Федоров техникалары да күптәннән эшкә әзер инде. Механизаторларның беренчесе тәҗрибәле булса, Николай бу техникада беренче ел гына эшли. Шуңа да ул Ефимовтан күп нәрсәгә өйрәнде инде.



Печән әйләндергеч агрегатлар тырнагычлар да эшкә әзер. Чабылган үлән бераз кипшенүгә үк әлеге техника да басуда сынау үтә башлаячак.

- Техника иске, таушалган. Шуңа да аларны «Сельхозтехника» АҖенә ремонтка җибәрмәдек. Үзебез төзәткәне ышанычлырак, өстәвенә арзангарак та төшә,- диде безгә хуҗалыкның баш инженеры Олег Николаевич Миронов.

Терлек азыгы хәзерләү сезоны башланды. Шул уңайдан ассоциация рәисе Х.Хәмидуллин фикерен дә ишетәсебез килгән иде.

- Былтыр әзерләгән терлек азыгыбыз быелга да калды әле. Шулай да быел тагын ел ярымлык запас туплауны максат итәбез,- диде ул.

Без авылдан киткәндә, печән чаптыручы егетләрнең «Беларусь»ләре күпьеллык үлән мәйданнарының икенче басуында хәрәкәт итәләр иде инде. Әле яңа гына үсеп утырган үлән калын тезмнәргә «ятә» барды.

**Р.ГИНЯЕВА.**

**Рәсемдә: механизатор Сергей Куприянов һәм Виталий Герасимов.**

## Булышучылар күп

Район хуҗалыкларында шикәр чөгендере сирәкләүгә керештеләр.

«Заря» кооперативлар хуҗалыгында шикәр чөгендере 215 гектар мәйдан били. Терлек азыгы максатларында исә тагын 20 гектарда чөгендер үстерелә. Бүгенге көндә барлык мәйданнарда да эш башланды. Авыл эшчәннәренә ярдәмгә мәктәп педагоглары, җирле үзидарә Советы, хуҗалыкның хисап хезмәткәрләре, шулай ук пенсионерлар да килгәннәр. Мәктәп укучылары да җәйге практикаларын басуда эшләп, берүк вакытта туган хуҗалыкларына булышып үткәрергә җыеналар.

## КИСКЕН СИГНАЛ

## Сөт кайда - арта, кайда - ачый

Район терлекчеләренең продукция җитештерүне арттыруын телдән төшермичә мактап кына торганда, туды куйды бер бәла: сөт ачый. Әлбәттә, бөтен җирдә түгел, санитар чисталык җитмәгән хуҗалыкларда. Соңгы 5 көндә, мәсәлән, «Комбайн» КХАсының 5250 кг. сөте кире кайтарылды. «40 лет Победы», Әлмәт, «Агрохимсервис»ның «Сөлчә» ярдәмче хуҗалыгыннан озатылган продукция дә (1200 - 2836 кг.) ачылыгы чиктән тыш югары булу сәбәпле, комбинатка кабул ителмәде.

Транспорт чыгымнарын исәпләмәгәндә дә күпме чыгым: бер «Комбайн» гына да шул рәвешле 5,8 млн. акчасын җилгә очырды.

Шулай ук артык микәнни әлеге хуҗалыкларга бу миллионнар?

## Норлатта - сәүдә - промышленность Палатасы филиалы

Май уртасында район тормышында җитди һәм мөһим вакыйга булды: район хакимияте башлыгы Ф.С.Сибагатуллин күрсәтмәсе буенча Норлатта Татарстан Республикасы сәүдә - промышленность Палатасының филиалы ачылды. Яңалыкның максатлары өметле: иң әүвәл, кече бизнеска дөньякүләм ярдәм, ул исә җирле эшмәкәрлек үсешенә, катлаулы икътисадый шартларда ныгытып аякка басуга этәргеч бирәчәк. Ахыр чиктә, ул район бюджетына салым кертемнәре артуга, шул рәвешле өлгергән социаль проблемаларны хәл итүгә мөмкинлек бирәчәк. Фактка Норлат филиалы директоры Ренат Вакиф улы Моратов түбәндәге аңлатманы бирә:

- «Ярдәм» сүзе гамәлдә эшмәкәрләр проектын финанслауны аңлата. Реаль идея туган икән - килегез, без сезнең тәкъдимнәрегезне игътибар белән караячакбыз. Башлангыч анализны үткәрәчәкбез. Икенчел анализ ясауны ТР Палатасы экспертлары үз өсләренә алалар. Практикада икътисадый ярдәм Татарстан Республикасы Президенты каршында оештырылган махсус фонд средстволарына башкарылачак. 55 мең долларга кадәр ссуда өч елга еллык 8 процент шарты белән бирелә. Дүшәмбе, 16 июнь көнне Норлатка сәүдә - промышленность экспертлар группасы килә, алар бизнес - планны ачыкларга ярдәм итә алалар. Консультация әңгәмәсе шул ук көнне район мәдәният йортының кече залында булачак. Контактлы телефоннар: 2 - 12 - 17, 2 - 11 - 72. Шалтыратыгыз, килегез.

Шунысын да әйтик: Норлаттагы бу филиал - республика күләмендә алтынчы. Моннан тыш, тагын 3 вәкиллек бар.

**Т.НАЗАРОВА.**

## *Бәйрәмегез белән, шәфкать ияләре!*

***Ел саен июньнең өченче якшәмбесендә медицина хезмәткәрләре иң истәлекле көннәре - профессиональ бәйрәмнәрен билгеләп үтәләр. Халык депутатларының район Советы, район хакимияте халык сәламәтлеге сагында торучы табиблар һәм урта медицина хезмәткәрләренең күпсанлы отрядын чын күңелдән тәбрик итә. Һәм бу котлауларга район үзәк һәм биш участок шифаханәләренә, фельдшер - акушер пунктлары һәм профилакториеләрдә медицина хезмәткәрләре хезмәтеннән файдаланган һәркем кушыладыр дип ышанабыз.***

***Ак халатлы шәфкать ияләре, сезнең хезмәтегез катлаулы һәм гадәттән тыш җаваплы. Сездән югары квалификация, белем сандыгыгызны һәм күнекмәләрегезне даими тулыландырып тору гына түгел, югары әхлак принципларына ия булуыгыз да сорала. Шунысы куанычлы, районда сәламәтлек саклау системасының дәвалау профилактикасы елдан - ел камилләшә, диагностика һәм дәвалауның яңа ысуллары кулланылышка керә, медицина хезмәткәрләренең һөнәри осталыгы үсә. Без сезнең өлкәдә килеп чыккан хәлиткеч проблемаларны хәл итүдә ярдәм итәргә әзербез, ахыр чиктә болар халык сәламәтлеген саклау һәм үлемнән коткару кебек игелекле бурычны үтәүгә хезмәт итәчәк.***

***Хөрмәтле медицина хезмәткәрләре!***

***Хезмәтегезне, бурычыгызга тугрылыклы калуыгызны бәяләп, эшегездә яңадан яңа уңышлар, ныклы сәламәтлек, гаилә бөтенлеге, шатлык һәм бәхет телим.***

**Ф.СИБАГАТУЛЛИН,**
**халык депутатларының Октябрь район Советы рәисе, хакимият башлыгы.**

## З.Шабаев: «Халыкка һәрвакыт медикның җылы куллары, тәмле сүзе кирәк булачак».



**Шабаев Зәкәрия Абдуллович. 24 ел Октябрь районы үзәк шифаханәсенең баш табибы булып тора. Тумышы белән Мордва республикасыннан. 1966 елда Казан Дәүләт медицина институтының стоматология факультетын тәмамлый һәм безнең районга эшкә җибәрелә. РФнең атказанган табибы, «Сәламәтлек саклау отличнигы», Кызыл Хач һәм Ярымай съезды делегаты. «Мактау билгесе ордены» белән бүләкләнгән.**

**Медицина хезмәткәрләренең һөнәри бәйрәме алдыннан без аның белән әңгәмә кордык.**

**- Зәкәрия Абдуллович, Сезне профессиональ бәйрәмегез белән котларга рөхсәт итегез. Әйтегез әле, Сезнең өчен аның асылы нидә?**

- Медицина хезмәткәре ул үз җилкәсендә җәмәгать бурычларын күтәрүче кеше. Авыруларны дәвалау һәм үлемнән коткарып тулы канлы яшәүгә, хезмәткә кайтару, яңа чирләрне булдырмау - аларның көндәлек һәм мәҗбүри эше. Әмма шул гадәтилек, көндәлектә никадәр игелек, мәрхәмәт, энтузиазм һәм үз - үзеңне аямау күренеше ята.

Җиребезне сәяси, икътисадый вакыйгалар ничек кенә тетрәтмәсен, халыкка һәрвакыт медикның җылы куллары, терелү өмете һәм шатлыгы бүләк итә торган сүзе кирәк булачак. Шуңа да медицина хезмәткәре көне халыкара бәйрәмнәрнең берсе, дигән фикердә мин.

**- Шул игелекле вазифаны тормышка ашырырлык шартлар җитәрлекме? Гомумән, районыбызда сәламәтлек саклау органы бүген нинди хәлдә?**

- Дүрт ел яңа финанс шартларында, чынлыкта кризис хәлендә районда сәламәтлек саклау системасы үзен бербөтен итеп саклау өчен зур көч куя.

(Ахыры 2 нче биттә).

# БОЛГАРНЫҢ КАДЕРЛЕ КИЧЛӘРЕ

***Татар яшьләре һәм мәктәп укучыларының 30 - 31 май көннәрендә шәһри Болгарда уздырылган традицион җыенында быел безнең район вәкилләре дә катнашып чыгыш ясадылар, хәтта бүләкләргә дә лаек булдылар.***

Болгар җыенында катнашу теләге узган елгы җыеннан соң туган иде. Сәхнәдә чыгыш ясаган сәләтле балаларны, мәйданда көч сынашкан егәрле егетләрне күргәч, ирексездән: «Бездә азмы әллә мондыйлар! Нигә соң без читтә калганбыз? Әнә, ничәшәр йөз чакрым ара үтеп, республиканың кайсы гына чикләреннән җыелмаганнар монда!»- дигән үпкәле - көнләшүле фикергә килгән идек. Быелгы яз якынлаша башлагач, мәктәпләрдән (бигрәк тә тел, әдәбият, тарих укытучыларыннан) әлеге җыен һәм аның программасы белән кызыксынучылар шактый булды. Шул уңайдан, үзләренең иң оста башкаручыларын да тәкъдим иттеләр алар.

**Һ**әм, ниһаять, көтелгән көн килеп тә җитте. Җыенчылар утырган 4 автобус, район дәүләт автоинспекциясе хезмәткәрләре озатуында, Татарстан әләмен җилфердәтеп, көн үзәге җиткәндә изге сәфәргә кузгалды.

Юлда сәфәрчеләргә республикабызның башка район вәкилләре дә килеп кушылды. Ә инде Болгарда - җыен мәйданында безне үзебезнең Колбай Мораса мәктәбе укучылары каршы алды. Алар «Алга» КХАсы ярдәме белән үзләренең барлык югары класс укучыларын Болгарга алып килү мөмкинлеген тапканнар.

Бәйрәмнең төп хуҗалары - Чаллы эшмәкәрләре бертуган Рәфис һәм Нәфис Кашаповлар килгәннән соң җыенны ачып җибәрделәр. Бу минутларда октябрьлеләр аеруча горур иделәр. Чөнки бәйрәмнең хәерле сәгатьтә ачылуын белдереп яңгыраган моңлы кичке азанны әйтү хокукы Колбай Мораса урта мәктәбе укучысы Инсаф Садретдиновка бирелде.

Шәһәребезнең 1 нче рус - татар урта мәктәбеннән 2 - В татар классы (җитәкчесе Г.Н.Садретдинова) укучыларының «Болгар оныклары» дип аталган әдәби - музыкаль чыгышын да җыенчылар зур игътибар белән кабул иттеләр. Моннан тыш шул ук мәктәпнең III класс укучысы Рамил Мәҗитов һәм Яңа Әмзә урта мәктәбеннән Зилә Нәбиуллина гарәп телендә көйләп догалар уку ярышында да катнаштылар. Ә Зиләбез, шәрыкъ гыйлемен үзлегеннән генә өйрәнүенә карамастан мәдрәсәләрдә шул юнәлештә махсус белем һәм уку күнекмәләре алган балалар арасында беренчелекне яулады. Югары Норлат урта мәктәбеннән кызлар ансамбле якташларыбыз иҗатын тәкъдим итте. Алар Фәүзия Мөхәммәтова сүзләренә Рамил Мифтахов көй язган «Норлатым» һәм «Чияләр» җырларын башкардылар. Колбай Мораса урта мәктәбеннән Гөлназ Рәхимова 76 яшьлек якташыбыз Җәвидә апа Мингалимова сүзләренә Роберт Андреев көй язган «Морасам» җырын башкарды. Бу көнне Җәвидә апа үзе дә сәхнәдә чыгыш ясап, яшьләргә шигъри фатихасын җиткерде. Моннан тыш безнең укучылар мөнәҗәтләр конкурсында катнаштылар, җырлар башкардылар. Шәһәребезнең 4 нче рус - татар мәктәп - гимназиясе укучыларының Болгарга багышланган рәсемнәре, 2 нче рус - татар мәктәп гимназиясеннән әдәби түгәрәккә (җитәкчесе Р.В.Яруллина) йөрүчеләрнең шәҗәрә үрнәкләре дә күргәзмәгә тәкъдим ителде. Колбай Мораса урта мәктәбеннән Эльмира Абдуллина үзенең «Болгарым» дигән шигырен сөйләде.





Яңа Әмзә урта мәктәбеннән Әнвәр Галим улы Фәссахов җитәкчелегендәге түгәрәкнең хезмәте - борынгы һөнәрчелекне гәүдәләндергән макетлар җыен күргәзмәсенең иң җәлеп иткән урыны булды. Күргәзмәгә куелган туку станогы, чыпта сугу станогы, тире йомшарту җайланмасы һәм тимерче алачыгы җиһазлары һәммәсе чын тормыштагыча хәрәкәттә иде.

Шәһәребезнең беренче мәктәбеннән 2 - В классына һәм борынгы һөнәрчелек макетларының авторлар коллективына Кашаповлар махсус призлар тапшырдылар. Ә инде ялгыз башкаручыларга шулай ук истәлек бүләкләре бирелде.

Җыенның икенче көне дә күтәренке күңел белән башланды. Бу көнне һәммәбезне Сабан туе мәйданы көтә иде.

Төп ярыш көрәш мәйданында барды. Әлбәттә, ярыш хакимнәренең гаделлеге җитеп бетмәгән чаклар да аз булмады. Әмма шуңа да карамастан, егетләребез 6 тапкыр призлы урын яуладылар! Кемнәр алар дисезме? 35 кг.га кадәр үлчәүдә 1 нче урынны Киекле мәктәп - гимназиясе укучысы Илфат Хәсәншин, ә 2 нче урынны шәһәрнең беренче мәктәбе укучысы Айдар Гыймранов алды. 45 кг.га кадәр үлчәүдә Түбән Норлат мәктәбе укучысы Ранис Рәхмәтуллин 2 нче урынга чыкты. 65 кг.га кадәр үлчәүдә шул ук Түбән Норлат мәктәбеннән Хәниф Мәүлетов 2 нче урынны, ә Илназ Вәлиев 3 нче урынны алды. Бу егетләрнең һәммәсенә бертуган Кашаповлар истәлекле бүләкләр тапшырдылар. Ә инде 65 кг.нан югары үлчәүдә Югары Норлат урта мәктәбеннән Айрат Мусин беренчелекне алгач, җыен хуҗалары аңа видеомагнитофон бүләк иттеләр. Бу егетебез җыенның абсолют батыры исемен алу өчен көрәштә дә 2 нче урынга чыкты.

Җыенның ахырында бүләкләр тапшырганда «Октябрь районы» дигән исем кабат - кабат ишетелгән саен мәйдан гөр килде. Районыбызның һәр вәкиле - олыбыз - кечебез чиктән тыш горурлык кичердек бу минутларда.

Ике көнлек бәйрәм - җыен бер мизгел генә кебек узды да китте. Картлар әйтмешли, аллага шөкер, һәммәбез дә - бу сәфәрдән районыбыздан 176 кеше катнашып, шуның 150се укучы балалар, калганы - ата - аналар иде бит! - исән - сау әйләнеп кайттык.

**С**әфәрдән соң туган кайбер фикерләрне дә киң җәмәгатьчелеккә җиткерәсе килә. Бердән, балаларыбызны туплап, шундый республика күләмендәге җыенда катнаша алуыбызга сөендек. Чөнки балаларның иҗади сәләтләрен үстерү, аларны дөньяга чыгару, кеше арасына кертү, чыгыш ясарга өйрәтү, интеллектуаль үстерү һәм иң мөһиме - милли үзаң тәрбияләүдә иң нәтиҗәле чараларның берсе иде бу җыен.

Тагын бер як безнең өчен бик әһәмиятле иде: кызларыбыз - егетләребез бәйрәмдә милли татар киемнәреннән бик теләп йөрделәр, үз ана телебездә туйганчы сөйләштеләр, аралаштылар, җырлаштылар.

Әлбәттә, бу нәтиҗәләргә ирешү, укучыларыбызны шушы яңа дөньяга алып чыгу өчен материаль яктан да, рухи яктан да терәк бирүчеләргә зур рәхмәт. Ел буена әзерләнеп килсәк тә, район хакимиятенең хәер - фатихасы, хуплавы һәм ярдәме булмаса, транспорт белән тәэмин ителмәсәк, безгә бу сәфәргә чыгу насыйп булмый иде.

Сәфәргә җыенганда «Кондырча» һәм «Алга» КХАлары җитәкчеләренең үз мәктәп укучыларына булган мөнәсәбәте дә мактауга лаек. Чөнки алар үз укучыларын транспорт белән үзләре тәэмин иттеләр һәм мәктәпләреннән күбрәк укучының шушы җыенда катнаша алуына шартлар тудырдылар.

**С**оңгы сүз итеп, Норлат шәһәрендәге балалар - үсмерләр өчен физик әзерлек клубының (ДЮКФП) эшчәнлеге турында да фикер әйтәсе килә. Спорт ярышларында катнашкан укучыларыбыз һәммәсе дә - шушы клубта әзерлек узучы балалар. Алар төрле мәктәпләрдән булуларына карамастан, бер бөтен буларак хезмәт куйдылар, үзләренең еллык тырышлыкларының нәтиҗәсен күрсәттеләр.

Гомумән алганда, бу форум безнең укучылар өчен беренче адым, ягъни стартка басу гына әле ул. Димәк, исән - сау булсак, чыгыш ясыйсы көннәребез дә, алкышлар яулыйсы мәйданнарыбыз да алда әле безнең. Бары тик яшәү кыйблабыз үзгәрмәсен дә, терәк - таянычларыбыз озакка булсын дигән теләктә калабыз.

**К.ҖАМАЛЕТДИНОВА,**
**район мәгариф бүлеге мөдиренең милли мәсьәләләр буенча урынбасары.**

**Рәсемнәрдә: Яңа Әмзә мәктәбе делегациясе; А.Мусин бүләк ала.**

## КОТЛЫЙБЫЗ!



*Кадерле әти - әниебез **Шәфыйк Шәмгун улы һәм Рәисә Мингата кызы Әбҗәлимовларны** туган көннәре белән ихлас күңелдән котлыйбыз. Сезгә бәхетләрнең олысын, шатлыкларның куанычлысын, балаларыгызның игелеген күреп, исән - имин тигезлектә бергә озак еллар яшәвегезне телибез.*

***Кызлары, кияүләре һәм оныклары.***



15 июньдә **Дөләфкәр Закир кызы Фәрхетдиновага** 90 яшь тула. Шатлыклы, сәламәт гомер телибез.

Әнкәй, сиңа бүген 90 тула,
Бар гөлләрем сиңа бүләгем.
Изге йөрәк биргән ходама рәхмәт,
Тыныч булсын күңелең, терәгем.

**Балалары, оныклары.**

*Кадерле әниебез **Хатирә Хөснелгата кызы Хәбибуллинаны** юбилее белән котлыйбыз.*

*Җитмеш тапкыр карлар яуган,*
*Җитмеш тапкыр килгән яз.*
*Юлларыңда шатлык юлдаш булып,*
*Тормыш күгең булсын гел аяз.*
*Юбилееңкотлы булсын, әни!*
*Гомерең үтсен бары шатлыкта.*
*Кайгы күрмә мәңге, чирне белмә*
*Һич бирешмә, әнкәй, картлыкка.*
***Тормыш иптәшең, балаларың,***
***килен - кияүләрең, оныкларың.***



## Белдерүләр

### Сатабыз

**Мунча өчен бура**. Энгельс ур., 24 нче йортка мөрәҗәгать итәргә.

***

**Сүтелгән хәлдә төзелеш материаллары белән (такта, ДВП, түбә калае) щит йорт комплекты**. Ульяновск өлкәсе, Яңа Малыклы районы, Яңа Чирмешән поселогы, Мир урамы, 8 нче йортка мөрәҗәгать итәргә.

***

**Минитрактор, мотоблок чапкычлары, бәрәңге, кыйммәт түгел**. Тел.: 5 - 18 - 85.

***

**1996 нчы елның декабрендә чыккан ВАЗ - 2106 машинасы, 4 мең км. юл үткән.** Тел.: 2 - 18 - 89 (17 сәгатьтән соң).

***

**Ашыгыч рәвештә ВАЗ - 21053, барлык материаллары белән 3,5 х 5,5 метрлы мунча бурасы, нарат такталар, кыйммәт түгел**. 40 лет Октября ур., 41.

***

**УАЗ - 452 Д (бортлы) автомобиле.** Тел.: 2 - 11 - 44.

***

**ВАЗ - 2101гә беренче комплект двигатель, кулланылган, яхшы хәлдә.** Советская ур., 189 - 29.

***

**Норлат - Октябрь азык комбинатында сатуда 1,25 х 2,75 метрлы 26 мең сумнан ДВП (яки иткә алмаштырыла), 50 мм.лы куб. м. 550 меңнән такта бар.**

Белешмәләр өчен тел.: 2 - 21 - 15 (директор), адрес: Завод ур., 31.

***

**Каравыл Тавы авылында йорт яны корылмалары белән кирпеч йорт сатыла яки фатирга алмаштырыла.** Тел.: 5 - 13 - 68.

***

**Шәхси йорт бер бүлмәле фатирга яки шәхси йорт һәм бер бүлмәле фатир - ике бүлмәлегә.** Адрес: Октябрьская ур., 120 - 16, 18 сәг.тән соң.

***

**Норлат сәүдә базасында түмәрләп һәм ваклап цинкланган савыт - саба: чиләк, 9 л.лы - 25 мең сум, 12 л.лы - 28 мең сум, 13 л.лы таз - 30 мең сум, озынча 17 л.лы - 36 мең сум, ванна - 85500 сум, бак - 70900 сум, «Волга» кер юу машинасы 750 мең сум.**

### Табучы юкмы?

**Сенькин Анатолий Николаевич исеменә бирелгән машина йөртү таныклыгын табучыны бүләк бәрабәренә Абрыскино авылына иясенә кайтаруын сорыйбыз**, тел.: 4 - 22 - 36.


БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

**Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы, 19.**

**Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, җаваплы сәркәтип - 2-18-67, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия, реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

***Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.***

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2089 данә. Заказ № 7640.